ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына яшьләрнең хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда ярдәм итү зарурлыгына аеруча игътибар биреп, дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү һәм гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Алкогольле эчемлекләр, никотинлы продукция һәм наркотик чаралар куллануны профилактикалауга юнәлдерелгән тематик чаралар уздыру эшен активлаштырырга.

4.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, иҗтимагый эшчәнлеккә җәлеп ителмәгән яшьләр белән эшләүгә

аеруча игътибар биреп, аңлы рәвештә патриотизм формалаштыру максатларында яшьләр белән эшне көчәйтергә.

4.3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән берлектә:

4.3.1. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында, шәһәр округында яшьләр иҗтимагый оешмалары белән хезмәттәшлекне активлаштырырга.

4.3.2. Яшьләр (яшүсмерләр) клубларының матди-техник базасын ел саен яңарту мәсьәләсен карарга.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. 2024 елның 19 августындагы 674 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы халкының финанс грамоталылыгын арттыру һәм финанс культурасын формалаштыру» региональ программасы кысаларында чараларны гамәлгә ашыру эшен көчәйтергә.

5.2. Чыгарылыш курс студентлары өчен һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында социаль-һөнәри адаптация буенча дәресләр үткәрүне оештырырга.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентына:

6.1. Актив гражданлык позициясен, сәламәт яшәү рәвешен, сәяси грамоталылыкны һәм милли толерантлыкны популярлаштыру максатларында яшьләр белән эшне дәвам итәргә.

6.2. Хокукый тәрбия бирүгә булыша торган кыйммәтләр системасын булдыру эшен, шул исәптән кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын аңлы рәвештә аңлауны үстерү өлешендә, көчәйтергә.

6.3. Яшьләрне агарту эшен үстерү чараларын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

7. Республика башкарма хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 286-VII ДС